СОВЕТ ТАВЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Нагорная, д.70, с. Тавели,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422160

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАУИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Тау өсте урамы, 70 йорт, Тауиле авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы, 422160

Тел. (факс): (85563) 2-67-25 e-mail: Tavel.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение Карар

“13” апрель 2021 ел. № 1-7

### Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге Советының 2020 нче елның 19 февралендәге № 4-51 карарына үзгәрешләр кертү турында

Мамадыш муниципаль районы прокуратурасының 2021 елның 20 мартындагы № 02-08-02-2021 протесты, 2020 елның 31 июлендәге «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 259-ФЗ номерлы Федераль закон, 2020 елның 26 декабрендәге «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнарның, муниципаль вазыйфаларны яисә җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе хакында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге Советының 2020 нче елның 19 февралендәге № 4-51 карары белән расланган Муниципаль берәмлектәге контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль берәмлектәге контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын яисә җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2.3 пунктның 3 пунктчасына «оешмалар» сүзләреннән соң «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында Интернет

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә  Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының http:/ https://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге башлыгы В.И.Ивановка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Тауиле  авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /В.И.Иванов/